МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.03.2019 г.Казань № 45/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасын раслау турында” 2017 елның 31 мартындагы 70/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу турында” 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында” 2018 елның 17 гыйнварындагы 17 номерлы карары нигезендә **БОЕРАМ:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасын раслау турында” 2017 елның 31 мартындагы 70/2-пр номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 02.05.2017 № 98/2-пр, 31.10.2017 № 243/2-пр, 15.03.2018 № 53/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) кертелә торган үзгәрешләрне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Эш башкару һәм контроль бүлегенә (Р.К.Баһаутдинова) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл

хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына җиткерергә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Р.Р. Хәбиповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары - министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2019 елның 11.03. 45/2-пр номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасын раслау турында” 2017 елның 31 мартындагы 70/2-пр номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасын раслау турында” 2017 елның 31 мартындагы 70/2-пр номерлы боерыгының (алга таба - Боерык) кереш өлешендә “2013 - 2020 елларга” сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Боерык белән расланган “2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасында (алга таба - Программа):

Программаның паспортында:

«Программаны эшләү өчен нигез» графасында «2013 - 2020 елларга» сүзләрен «2013-2021 елларга» сүзләренә алыштырырга;

«Программа чараларының тасвирламалары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Теркәлү датасыннан кимендә 12 ай эшләүче һәм авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм кооперативлар әгъзалары (ассоциация әгъзалыгыннан тыш) хокукларында эшкәртү яисә сату буенча кимендә 10 авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесен берләштерүче, табышының кимендә 70 проценты күрсәтелгән продукцияне эшкәртү һәм сату эшчәнлеген гамәлгә ашырудан барлыкка килә торган эшкәртү һәм (яисә) сату буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына яки кулланучылар җәмгыятьләренә (кооперативларына) грантлар бирү өчен федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү.

Матди-техник базаны үстерү – яңа технологияләрне гамәлгә кертүгә һәм эш урыннары булдыруга, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-

техник базасын төзүгә, реконструкцияләүгә, модернизацияләүгә яисә сатып алуга юнәлдерелгән чаралар, шул исәптән:

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү һәм сатуга әзерләү буенча җитештерү объектларын сатып алуга, төзүгә, ремонтлауга, реконструкцияләүгә яисә модернизацияләүгә;

авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен билгеләнгән җитештерү объектларына җайланмалар һәм техника сатып алуга, аларны монтажлауга, шулай ук чыгарыла (җитештерелә һәм эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатына һәм иминлегенә лаборатор анализ ясау өчен һәм ветеринария-санитария экспертизасы уздыру өчен җитештерү контроле лабораторияләрен җиһазлау өчен җайланмалар сатып алуга. Күрсәтелгән җайланмаларның һәм техниканың исемлеге Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана;

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын транспортировкалау өчен, аларны ташыганда һәм сатканда аларның сакланышын тәэмин итү өчен махсус транспорт, фургоннар, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, контейнерлар сатып алуга. Күрсәтелгән техниканың исемлеге Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана;»;

1 бүлекнең беренче абзацында «2013 - 2020 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 бүлекнең дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

4 бүлектә:

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Теркәлү датасыннан кимендә 12 ай эшләүче һәм авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм кооперативлар әгъзалары (ассоциация әгъзалыгыннан тыш) хокукларында эшкәртү яисә сату буенча кимендә 10 авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесен берләштерүче, табышының кимендә 70 проценты күрсәтелгән продукцияне эшкәртү һәм сату эшчәнлеген гамәлгә ашырудан барлыкка килә торган эшкәртү һәм (яисә) сату буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары яки кулланучылар җәмгыятьләре (кооперативлары) Программада катнашучылар булалар.

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын сайлап алуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) боерыгы белән расланган конкурс комиссиясе гамәлгә ашыра»;

4.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7. Кооперативларның матди-техник базасын үстерүгә грант – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2013-2021 елларга Татарстан

Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу" дәүләт программасын раслау турында" 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган "2013-2021 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу" дәүләт программасы нигезендә федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан кооператив счетына аның дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре кысаларында кайтарылмый торган чыгымнарын финанслашу өчен бирелә торган акчалар ул.

Программада катнашучы грантны түбәндәгеләргә юнәлтергә мөмкин:

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү һәм сатуга әзерләү буенча җитештерү объектларын сатып алуга, төзүгә, ремонтлауга, реконструкцияләүгә яисә модернизацияләүгә;

авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен билгеләнгән җитештерү объектларына җайланмалар һәм техника сатып алуга, аларны монтажлауга, шулай ук чыгарыла (җитештерелә һәм эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатына һәм иминлегенә лаборатор анализ ясау өчен һәм ветеринария-санитария экспертизасы уздыру өчен җитештерү контроле лабораторияләрен җиһазлау өчен җайланмалар сатып алуга. Күрсәтелгән җайланмаларның һәм техниканың исемлеге Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана;

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын транспортировкалау өчен, аларны ташыганда һәм сатканда аларның сакланышын тәэмин итү өчен махсус транспорт, фургоннар, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, контейнерлар сатып алуга. Күрсәтелгән техниканың исемлеге Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана;».

3. Боерык белән расланган "2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү" ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә грантлар бирү турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктта «2013 - 2020 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3 пунктта:

икенче абзацта «2013 - 2020 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы – теркәлү датасыннан кимендә 12 ай эшләүче һәм авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм кооперативлар әгъзалары

(ассоциация әгъзалыгыннан тыш) хокукларында эшкәртү яисә сату буенча кимендә 10 авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесен берләштерүче, табышының кимендә 70 проценты күрсәтелгән продукцияне эшкәртү һәм сату эшчәнлеген гамәлгә ашырудан барлыкка килә торган эшкәртү һәм (яисә) сату буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы яки кулланучылар җәмгыяте (алга таба - кооператив) ул;»;

2 бүлектә:

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2 Грантның максималь күләме, өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча, бер кооперативка 70 млн. сумнан артык булмаган һәм Чыгымнар планында күрсәтелгән чыгымнарның 60 процентыннан артык булмаган күләмдә тәшкил итә»;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәгә:

«2.4. Грантлар кооперативларның матди-техник базасын үстерүгә дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре кысаларында кайтарылмаган түбәндәге чыгымнарны финанслашуга бирелә:

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү һәм сатуга әзерләү буенча җитештерү объектларын сатып алуга, төзүгә, ремонтлауга, реконструкцияләүгә яисә модернизацияләүгә;

авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен билгеләнгән җитештерү объектларына җайланмалар һәм техника сатып алуга, аларны монтажлауга, шулай ук чыгарыла (җитештерелә һәм эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатына һәм иминлегенә лаборатор анализ ясау өчен һәм ветеринария-санитария экспертизасы уздыру өчен җитештерү контроле лабораторияләрен җиһазлау өчен җайланмалар сатып алуга. Күрсәтелгән җайланмаларның һәм техниканың исемлеге Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана;

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын транспортировкалау өчен, аларны ташыганда һәм сатканда аларның сакланышын тәэмин итү өчен махсус транспорт, фургоннар, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, контейнерлар сатып алуга. Күрсәтелгән техниканың исемлеге Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана;»;

2.5 пунктның «н» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«н) матди-техник базаны үстерүгә грантны кабат алу элек алынган грант тулысынча тотылып беткән датадан соң 12 узгач кына мөмкин;»;

3 бүлекнең 3.1.7 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

5 бүлектә:

5.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.10. Конкурс комиссиясе мөрәҗәгать итүчеләр тапшырган документларны анализлау нигезендә, түбәндәге критерийларга таянып, конкурста җиңүчеләрне билгели:

| т/с № | Критерий исеме | Күрсәткечләр | Балларда бәяләү |
|---|---|---|---|
| 1 | Конкурс буенча сайлап алуда катнашу өчен заявка бирелгән вакытка мөрәҗәгать итүче милкендә һәм (яисә) 5 елдан кимрәк булмаган озак сроклы арендада авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен билгеләнгән җитештерү биналары булу | юк | 0 |
| | | 300 квадрат метрга кадәр | 5 |
| | | 300 квадрат метрдан күбрәк | 10 |
| 2 | Һәр 3 млн. сум грант күләменә эш урыннары булдыру | 2 | 5 |
| | | 3 һәм аннан күбрәк | 10 |
| 3 | Бизнес-план нигезендә үзен аклау срогы | 5 елдан күбрәк | 0 |
| | | 3 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| | | 3 елга кадәр | 10 |
| 4 | Матди-техник базаны үстерүгә чыгымнар планыннан үз акчалары күләме | 41-45 процент | 5 |
| | | 45 проценттан артыграк | 10 |
| 5 | Кооператив әгъзалары саны | 11-15 әгъза | 5 |
| | | 15 әгъзадан күбрәк | 10 |
| 6 | Кооператив җитәкчесенең эшлекле сыйфатларын бәяләү, һөнәри осталык, социаль һәм бюджет җаваплылыгы | Иң югары балл – 20 | |
| 7 | Кооперативның хисап чорында кереме | 500-1000 мең сум | 5 |
| | | 1 млн. сумнан күбрәк | 10» |

5.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.11. Баллар бары тик тегелгән документлар буенча гына исәпләнә, конкурс комиссиясе утырышына тапшырылган документлар балл суммасына кертелми. Иң күп җыелган баллар 80гә тиң. Конкурс комиссиясе тарафыннан уңай карар чыгару өчен 35 балл җыярга кирәк. Иң күп баллар җыйган мөрәҗәгать итүчеләр сайлап алу конкурсында җиңүчеләр булып танылалар.».

Нигезләмәгә 8 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 31.03.2017 № 70/2-пр боерыгы белән расланган 8 нче кушымта

Конкурс комиссиясе рәисе

Р.Р. Хәбипов ________________
(имза)

20___елның «_____» ___________________

**Татарстан Республикасы __________ муниципаль районының**

____________________________________________________________

(кооператив исеме)

**матди-техник базасын үстерүгә**

**ЧЫГЫМНАР ПЛАНЫ**

| т/с № | **Чыгымнар статьясы исеме** | **Финанслау чыганаклары, мең сум** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Бары-сы | шул исәптән | |
| | | | грант, 60 процент | үз акчалары |
| 1 | Авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, сатуга әзерләү буенча җитештерү объектларын сатып алу, төзү, ремонтлау, реконструкцияләү яисә модернизацияләү. | | | |
| 2 | Авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен билгеләнгән җитештерү объектларына җайланмалар һәм техника сатып алу, аларны монтажлау, шулай ук чыгарыла (җитештерелә һәм эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатына һәм иминлегенә лаборатор анализ ясау өчен һәм ветеринария-санитария экспертизасы уздыру өчен җитештерү контроле | | | |

| | |
|---|---|
| | лабораторияләрен җиһазлау өчен җайланмалар сатып алу. |
| 3 | Авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын транспортировкалау өчен аларны ташыганда һәм сатканда аларның саклanышын тәэмин итү өчен махсус транспор фургоннар, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, контейнерлар сатып алу. |
| | **Барысы:** |

Кооператив җитәкчесе _________________ _________________________

(имза) (Фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Мөһер урыны
(булса)».